Балалар журналы

ISSN 0868-4545

Салават күпере



Бисмиллаһир-рахманир-рахим!

Хөрмәтле әти-әниләр,
мөхтәрәм әби-бабайлар,
газиз милләттәшләребез,
әссәламегаләйкүм!

Менә без XXI гасырга атладык.

Алда ниләр көтә безне? Барыр юлларыбыз нинди булыр? Яңа гасырның һәр яңа көне, һәр яңа елы ничек каршылар безне?

Юлларыбыз сикәлтәле булмасмы, урау юлларга кереп адашмабызмы, кыен чакларга юлыкканда тугры дусларыбыз, аерылмас юлдашларыбыз бездән йөз чөермәсме, мәрхәмәтле, миһербанлы кешеләр әүвәлгечә ярдәмгә килүдән ваз кичмәсме, үзебез, заманга сылтап, явызлык, хөсетлек, көнчелек тарафдарларын ишәйтеп ялгышмабызмы, күрәсе төшләребезгә мәхшәрләр кереп йөдәтмәсме, газиз нарасыйларыбызның, бәгырь кисәкләребезнең балачак күген бер дә бер көнне дәһшәтле болытлар каплап алмасмы...

Юк, юк, һич кенә дә алай була күрмәсен иде берүк. Яманлыкның күзе тимәсен иде.



© "Салават күпере", 2001 ел



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Йа Хода!

Безнең садә күңелләребезгә, саф җаннарыбызга Шәфкатьлелек, Эчкерсезлек, Изгелек, Тынычлык вә Матурлыклар гына иңдерсәң иде, аңнарыбызга якты уйлар, яхшы ниятләр генә сеңдерсәң иде!

...Без Яңа гасырга атладык. Киләчәккә барышыбыз. Атлаган җиребез – бәрәкәтле, юлларыбыз – уң, адымнарыбыз ышанычлы булыр, шәт, иншалла.

Юраган – юш килә, диләр. Киләчәгебезне, күрәчәгебезне яхшыга юрыйк. Яхшыга гына.

Амин!

Һәркемнең тормыштан өлеше бар,
аласы көмеше бар.

Кадерле малайлар һәм кызлар!

Менә Сез дә, сөекле әти-әниләрегезнең җылы кочакларына сыенып, аларның назлы, соклanулы карашларын тоеп, Яңа гасырга – XXI йөзгә аяк атладыгыз.

Киләчәк – Сезнеке!

Аның нинди булуы Сезнең үзегездән дә тора.

Сәламәт Акыл, Саф Күңел, Изге Ният Сезнең гомерлек юлдашларыгыз булсын!

Хәерле юл Сезгә, хәерле юл!




Юл теләге

Яңа гасыр яңалыгы белән,
Серлелеге белән кадерле ул.
Яхшылыкка, Яктылыкка ашкын –
Хәерле юл Сиңа, хәерле юл!

Алга да бар, үткәнгә дә кара,
Тарихыңны барла – хәтерле бул.
Аң-белемгә, гыйлемлеккә омтыл –
Хәерле юл Сиңа, хәерле юл!

Үгет-нәсихәтләр зыян итмәс:
Каты булма, йомшак бәгырьле бул.
Якты исмең синнән алда йөрсен –
Хәерле юл, Дускай, хәерле юл!

Сукмак юлга алып барыр,
юл халыкка алып барыр.



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Елан-малай, елан-кыз...

Әйе, Яңа гасырның Яңа елы – ЕЛАН елы.

Елан елында туган балалар акыллы, зиһенле була диләр.

Елан-малайга нечкә күңеллелек, хисчән булу, сөйкемлелек, шук-шаянлык хас. Ә Елан-кыз исә, барыннан да битәр, гүзәллеккә, матурлыкка ия.

Христиан илләрендә, шул исәптән бездә дә, Еланны бик өнәп бетермиләр. Бу аңлашыла да: Еланны без агулы дип, кеше тормышы өчен куркыныч җан иясе дип беләбез. Ә менә Азия илләрендә Еланга карата булган мөнәсәбәт уңай. Япониядә, мәсәлән, хатын-кызны мактаганда: «Кадерлем, син искиткеч елан!» – диләр...



Елан суыктан курка. Аның яшәешенә һава торышы да, ел фасыллары да гаять зур йогынты ясый. Шуңадырмы, Елан елында, аеруча эссе вакытта туган баланы «Бәхетле булыр!» – дип юрыйлар.

Рәссам Илдар НӘФИЕВ

Бер, ике, өч – бездә бөтен көч!

Сәгать чылтырады. Аның тавышын ишетеп, син уяндың. Әмма синең сикереп тору түгел, күзләреңне ачарга да исәбең юк әле. «Их, тагын бераз гына йокларга иде!» – дип уйлыйсың син. Ләкин бер нишләр хәлең юк – ясле-бакчага яисә мәктәпкә барасың бар. «Их, – дисең син янә, – кичә төнгә хәтле телевизор карамаган булсам, озак йоклаган булыр идем!» – дисең.

Шулвакыт әниеңнең ягымлы тавышын ишетәсең:

– Тор инде, балам. Уян! Ашарыңа әзер. Юынып алганчы, физзарядка ясыйсың бар!

Син инде дәү кеше. Әниеңнең икенче мәртәбә әйткәнен көтеп тормыйсың – җәһәт кенә аякка басасың.

Иртән күнегүләр ясауның организмыңа файдалы икәнен син бик яхшы беләсең. Төнлә, йоклаган чакта, безнең гәүдәбез ял итә, мускуллар йомшара, йөрәк һәм үпкә ярты көченә генә эшли. Аларны да «уятырга» кирәк. Физик күнегүләр безнең каныбызны тамырлардан тизрәк агарга, буыннарны язылырга, мускулларыбызны көч тупларга, үпкәләребезне ныграк суларга мәҗбүр итә.

Табигатьтәге һәр җан иясенә дә күнегүләр ясау кирәк. Эт яки мәченең ничек уянганын карагыз әле. Башта алар, сөякләре шыгырдарлык итеп, бөтен гәүдәләре белән киерелләләр, алгы, аннары арткы аякларын сузалар, аннан аркаларын бөгәләр...

Йә, без эт-мәчедән киммени?!

Башладык:

– Бер, ике, өч – бездә бөтен көч!





Сәламәт тәндә – сәламәт акыл.

Чү!

Карагыз әле, карагыз әле бер генә: нәни куяннар да физзарядка ясап азаплана түгелме соң?!

Әллә санамыш әйтеп, качышлы уйныйлар инде. Әйдәгез, яннарына сиздермичә генә барып, күзәтик әле, тыңлыйк әле үзләрен:

– Бер, ике, өч –
Бездә бөтен көч!

Дүрт, биш –
Безне җиңеп булмый һич!

Алты, җиде –
Куркаклар башын иде!

Сигез, тугыз, ун –
Алты бүре – алты тун!

Без тук бүген, бүре ач,
Әнә килә – тизрәк кач!



Рәссам Юрий ДЕНИСОВ

Күп белгәннең – башы авыртмас

Беренче киңәш:

Кыршау ал да, кулларың белән тотып, өскә күтәр. Аякларыңны иңбаш киңлегендә аерып куй. Кулларыңны кыршау тоткан килеш түбән төшер. Аннары кыршауны янә баш очына күтәр һәм, нығытып, өскә таба сузыл.



Икенче киңәш:

Туры бас, аякларыңны иңбаш киңлегендә аерып куй. Тезләреңне бөкмичә генә кулларыңның бармак очларын идәнгә тидереп ал. Иелгәндә сулышыңны чыгар, турайганда сулыш ал.



Рәссам Илдар НӘФИЕВ



И рәхәт барчабызга – күңелле бакчабызда!

Син балалар бакчасына йөрисең. Анда яшьтәшләрең белән төрле уеннар уйныйсың, укырга-язарга, кызыклы шигырьләр, әкиятләр сөйләргә, матур җырлар җырларга өйрәнәсең.

Сезнең арагызда төрлегез бар – шаяннарыгыз, кыюларыгыз, тапкырларыгыз, юашларыгыз... Бәлки әле «Бакчабызда бер бала бар...» дигән әлеге шигырьне сөйләүче малай кебек гаять «тыйнак» һәм бик «тәртипле»ләрегез дә бардыр...



Үзен үзе мактаган –
агач атка атланган.

Бакчабызда бер бала бар...

Бакчабызда бер бала бар –
Шундый да ипле инде:
Кайчак әбием әйткәндәй,
Бигрәк тәртипле инде!

Малайлар һәм кызлар белән
Бик әдәпле сөйләшә.
Үзендә булган тәм-томны
Барсына да өләшә.

Көчсезләрне кыерсытмый,
Рәнҗетми ул кызларны...
Ялгыш кына орынса да:
«Гафу ит!» – ди, кызарып.

Уйнаганда ул һәммәсен
Көлдерә, шаккаттыра.
Тәрбияче апабыз да
Гел аны мактап тора.

Ул баланың кем икәнен
Син белмисең, мин беләм:
Мактануны белми торган
Ул малай үзем булам!



Рәссам Лилия ЗОЛОНДИНОВА

Әйдәгез, уйныйбыз!

«Әби» һәм «кәбестәләр»

Балалар-«кәбестәләр», бер рәткә тезелеп, чүгәләп утыралар. Кәбестә алучы булып сайланган «әби»: «Кәбестә алырга дип килгән идем, яхшыларын сайлап алыйм әле», – дип, «кәбестәләр»нең иңбашларына нык итеп басып-басып ала. Кем егылып китә,



ул «черек кәбестә» була һәм уеннан чыгарыла. «Әби» моны кабат-кабат эшли. Иң ахыргача нык утырган бала «яхшы кәбестә» була.

Рәссам Илдар НӘФИЕВ





Бүген-кичә заманда,
Син бәләкәй чакларда,
Ике малай яшәгән ди,
Безнең-сезнең якларда.

Малайларның берсенең
Исеме Өлгер булган.
Икенчесе – Симерҗан ди,
Кыскартсак, Симер булган.



Өлгерҗан әнисенең
Һәр йомышын үтәгән:
Казлар куган, су китергән,
Чүп утаган түтәлдән.



Мин – малай, дип тормаган,
Савыт-саба юышкан.
Әтигә дә, бабайга да,
Әбигә дә булышкан.



Китаплар да укыган,
Биергә дә өйрәнгән.
Кечкенә энекәшенә
Әкиятләр сөйләгән.



Шашка, шахмат уйнаган,
Сәхнәләрдә җырлаган.
Тагын бик күп һөнәр белгән...
Кыскасы, тик тормаган.



Инде килик Симергә,
Ул ниләр эшли икән?
Улмы? Ул инде күптәннән...
Ятактан төшми икән.



Авыр чир йоккан аңа –
Бик каты чирли икән:
Ике сәгать ашагачтын,
Бер сәгать тирли икән.




Торып йөрер хәле юк –
Торса, бик тиз арый ди.
Йокламаган чакта гына
Телевизор карый ди.



Ашаганда хәтта ки
Кашык тоталмый икән.
Тук чагында һич кенә дә
Ризык йоталмый икән.



Үзе бик түземсезләнеп,
Сабантуйны көтә ди.
«Сабантуйда көрәшергә
Исәп бар!» – дип әйтә ди.



Белмим, белмим... Шул синең
Сүзне тыңласа инде:
«Хәрәкәттә – бәрәкәт!»не
Үзе аңласа инде...



Белем алу – энә белән кое казу

Син мәктәптә укыйсың – белем аласың. Борынгы бабаларыбыз: «Белем алу – энә белән кое казу ул», – дип әйтеп калдырган. Димәк, әлеге мәкальдән аңлашылганча, нык ихтыярлы, максатчан, тырыш һәм түземле кешеләр генә белемле була ала. Син дә, дускай, шундый булырга тырыш: белемгә омтыл, күп укы. Мәшһүр шагыйребез Сәгыйть Рәмиевнең канатлы шигъри гыйбарәсен һәрдаим истә тот:

Безне адәм иткән уку,
Адәмне алга илткән уку,
Илтеп күккә җиткән уку,
Уку, уку, уку...



Мәзәкләрдән гыйбрәт ал

Дәрестә ял итә

Тәнәфес вакытында Марат әллә ничаклы «эш башкарып» өлгергән: ике кызның чәченнән тарткан, өч малайны төртеп еккан, көчек куган, турниктан егылып төшкән. Кыскасы, дәрескә ул агарынып, хәле бетеп кереп утырган.

– Арыгансың бит, – дигән аңа сыйныфташлары.

– Зыян юк, мин дәрестә барыбер ял итәм бит, – дигән Марат.



Наданлык билгесе

Укытучы Сәлимәгә:

– Наданлыкның зыяны турында берәр мисал китер, – дигән.

– Әгәр чебен надан булмаса, «Чебеннәргә үлем!» дип язылган кәгазьгә килеп кунмас иде, – дигән Сәлимә.

Белем – бәхет ачкычы,
дәрәҗәнең ачкычы.

Син – супербала!?



Син өйдә. Мәктәптән ачыгып кайткансың, билгеле, – әниең яисә әбиең әзерләгән тәмле, татлы ризыкларны «ә» дигәнче ялт иттереп куйдың.

Хәзер инде сиңа, диванга ятып, хыялга бирелеп, ял итеп алсаң да ярый...

...Әйе, кинолардагы супергеройлар шикелле, син супербала (супермалай яки суперкыз) ди.

Әгәр теләсәң, әллә ниләр, әллә нәрсәләр эшли аласың...

Теләсәң, кибеткә барып, ипи-сөт алып кайта аласың.

Чишмәдән «ә» дигәнче су алып кайта аласың – теләсәң.

Әгәр теләсәң, ишегалдындагы көртне ялт иттереп көрәп куя аласың.

Утын кисә аласың, яруны әйткән дә юк!

Шәрран ярып җылап яткан энеңне, җә сеңелеңне юата аласың – әгәр теләсәң.

Буш вакытыңда мажаралы-мажарасыз китаплар укый аласың, бер тәпие былтыр ук какшаган урындыкны төзәтә аласың, идәнне себерә-юа аласың...


Тагын әллә нәрсәләр, әллә ниләр эшли аласың...

Әгәр теләсәң... Теләмисең генә.

Әллә телисең дә, эшлисеңдәме?!

Рәссам Илдар НӘФИЕВ





Вакыйф Нуриев

Киек Каз юлы

(Хикәя)

Марат өйләрендәге зур, бәллүр вазаны ватты. Ватты да урамга ычкынды һәм караңгы төшкәнче өенә кайтмады. Дөресрәге, кайтырга курыкты. Кирәген бирәчәк, күрмәгәнен күрсәтәчәк бит аңа әтисе әлеге ваза өчен.

Әнә ул урамда берүзе басып тора. Шулвакыт аның баш очында зур гына яктылык пәйда булды. Әнә ул җиргә якынлаша. Бәй, оча торган тәлинкә ич бу. Менә төшеп тә утырды. Люк ачылды. Көмеш каска кигән бер матур абзыйның башы калыкты.

– Нихәл, Марат. Ваза өчен борчылма. Әйдә безнең белән Эта Кассиопеи йолдызына. Без сиңа вазаның тагын да матуррагын бүләк итәрбез.

Хәлбуки, ул көнне күктән берни дә төшмәде. Әлеге очрашу малайның хыялы, фантазиясе иде. Әтисенең каешыннан әнә шулай котылырга теләде ул. Ә чит планетадан килүчеләр җирдә яшәүчеләрнең бөтен уй-гамәлләрен күреп-белеп торалар, имеш. Эта Кассиопеи йолдызы турында исә малай китаптан укыган иде. 1955 елда Американың Кентукки шәһәре янындагы бер фермага «тегеләр» бишәүләп киләләр. Аларга атып карыйлар. Берни дә булмый, тик тимер чыңы гына ишетелеп кала. Фермерларның сөйләвенә караганда, «чакырылмаган кунаклар» нечкә билле, киң күкрәкле, зур күзле һәм зур колаклы. Ә менә 1968 елда Испаниянең Зафра шәһәре янында күренгән «кунак» озын буйлы, озын куллы, янып торган яшел киемнән була.

Энэлолар каян килә соң? Марат күккә карады. Аңа бихисап йолдызлар күз кыса. Бу – Киек Каз юлы. Ул галәмдәге миллионнарча галактиканың берсе генә булырга мөмкин икән. Димәк, энэло хуҗаларының кайсыдыр бер йолдызда яшәп ятулары бик ихтимал. Ә Эта Кассиопеи йолдызы – шул фаразларның берсе. Ул кояшка охшаган, аның 480 елга бер әйләнеш ясый торган кечкенә генә иярчене бар, дип язганнар иде. Их, китәргә иде шунда, китәргә иде. Ваза...

– Улым, нишләп йөрисең? Кич бит инде.

Марат әтисенең тавышыннан куркып китте. Әтисенең исә эштән кайтып килеше икән.


– Әти, синең кечкенә вакытта өегездәге берәр әйберне ватканың булдымы?

– Мин ватмаган әйбер калмагандыр, улым. Бик шук идем.

– Әти, мин дә вазаны ваттым бит. Ялгыш ваттым. Син ачуланасың инде мине?

– Нишләп ачуланыйм. Баш ярылмаган, күз чыкмаган...

Әтиле-уллы бергә атладылар. Могҗизалы, серле Киек Каз юлы яктысы аларны өйләренә кадәр иркәләп-назлап озата барды.



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Халык сөйләр – сүзләр бетмәс,
күк-галәмдә серләр бетмәс.



Кадерле дускай!
Журналыбызның соңгы санында
(2000 ел, № 11-12)
без яшь рәссамнар өчен
«2001 нче елның иң яхшы рәсеме»
дигән бәйге игълан иткән идек.
Синнән иң яхшы, иң матур
рәсемнәреңне көтеп калабыз.
Уңышлар сиңа!

Шар

Шарым кулдан ычкынды, –
Кояшка барып җитте.
Балкыды, нурлар сипте,
Күңелемне җилкетте.
Караңгы булмас хәзер:
Төнлә дә яна башлар –
Күз кысар малайларга
Әллә кояш, әллә шар.

Ильяс Мәҗитов, 10 яшь.
Чувашия, Комсомол, Чичкан авылы.



Зәлия Гайфетдинова.
Кукмара.

«Мамыкь» һәм «ташъ»

(Мәзәк)

Укытучы:

– Самат, нигә син «мамык» сүзенә йомшаклык, ә «таш» сүзенә катылык билгесе куеп язасың?

Самат:

– Мамык – йомшак, ә таш каты булганга.

Гүзәл Гафарова.
Әгерҗе.



Ләйсән Әбелмәхҗанова, 8 яшь.
Лениногорск.



– Түзәбез әле, түзәбез...
Елый-елый чапканчы.
Әби! Тизрәк бал бир безгә,
Бал кортлары чакканчы!..
(Чаллы)



– Оныкка бияләйгә дип,
Көннәр буе җеп эрлим.
Ә аннан соң ял итәмен:
Чәй эчәм тирли-тирли...
(Апас, Каратун)

Конкурс! Мин бит бу?!





– Шатлыгым бар, шуңа көләм,
Әйдә, сез дә көлегез!
Күлмәктәге рәсем түгел,
Чын мәче бу – белегез!
(Актаныш, Татар Суыксуы)




– Авыз – ерык, күзләр – кысык,
Йөгереп йөреш әле:
Кәнфит суырып сизмәгәнмен –
Ыштаным юеш әле!
(Балтач, Карадуган)



– Сәгать унда суга кердем,
Чыктым кичке бишләрдә...
Чыксам, күрәм: киемнәр юк!
Белмим, хәзер нишләргә?
(Казан)





1. Зәһәр елан (Гадюка).
2. Күсейотар елан (Змея крысолов).
3. Питон.
4. Күзлекле елан (Кобра).
5. Буар елан (Удав).

Еланнар сурәте төшерелгән рәсемнән Филне, Крокодилны, Тавә кошын, Жирафны һәм Юлбарысны тап.

Рәссам Светлана ПРИВИНА



Гасырның Яңа елы булачак Елан елы!

Әйе, йолдызнамә буенча, быел – Елан елы.

Елан дигәннән, без аның хакында ниләр беләбез соң? Агулы-агусыз булуыннан, гәүдәсенең сыгылмалы-бөгелмәле икәнлегеннән, аяклары юклыгыннан... хәбәрдарбыз. Тагы?

Елан корсак өлешендәге тәңкәләре ярдәмендә хәрәкәтләнә, шуыша. Шул тәңкәләргә «таяныр-тотыныр» урын булмаганда (әйтик, пыялада) ул шуыша алмый.

Еланнар йөзә дә белә. Бик зур буар елан – анаконда яки бездәге тузбаш суда бик озаклап йөзәргә ярата. Гомерләре буена суда яши торган диңгез еланнары да бар.

Еланнар күкәй сала, шуннан кечкенә еланнар чыга.

Еланның ысылдавы ачуы килүдән түгел, ә «Мин монда!» дип кисәтүе генә. Шуңа күрә, аларга якын килмәвең хәерле.

Еланнар беркайчан да диярлек кешегә беренче булып ташланмыйлар. Алар көтелмәгән хәл аркасында гына – өсләренә ялгыш бассаң яки яшеренгән урыннарына кулыңны тыксаң гына чагалар.

Шулай да, көтмәгәндә еланнарга юлыккан очракта, алардан һәрвакыт сак булу беребезгә дә зыян итмәс.

Еланның агы да – елан,
карасы да – елан:
агына тисәң, карасы коткармас.

Салават күпере

1(131) — 2001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАТБУГАТ, ТЕЛЕРАДИОТАПШЫРУЛАР ЭШЛӘРЕ ҺӘМ МАССАКҮЛӘМ КОММУНИКАЦИЯ ЧАРАЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ

1990 елның март аеннан бирле чыга.

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства по делам печати, телерадиовещания и средств массовых коммуникаций РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке. Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта
Диләрә НӘҮРУЗОВА рәсемнәре.

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кечә яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм тесләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиесе. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 10.1.2001 ел.
Басарга кул куелды 10.1.2001 ел.
Кәгазь форматы 84x108 1/16.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Тиражы 16240 данә. Заказ А-1.
Бәясе килешү буенча.

POINT®

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

